**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«10» 11 2025 ел Яр Чаллы ш. № 3690

ТР Тукай муниципаль районы «Бәтке урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 29 статьясы 20 пункты, «Муниципаль мәгариф оешмалары хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 10 январендәге 4 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. ТР Тукай муниципаль районы «Бәтке урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 1 кушымта нигезендә расларга.
2. ТР Тукай муниципаль районы «Бәтке урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 2 кушымта нигезендә расларга.
3. Карарның гамәлдә булуы 2025 елның 01 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны ТР Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
5. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 19 ноябрендәге 5186 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Э.Р. Низамиевага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Л.Н. Маняпов

Муниципаль район Башкарма комитетының 2025 елның «10» 11 3690 номерлы карарына 1 кушымта

2025 елның 1 октябреннән ТР Тукай муниципаль районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү Бәтке урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ буенча түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бер тәрбияләнүчегә бәяләр прейскуранты

| № | Хезмәтнең исеме | Хезмәт бәясе (сум) | Хезмәт күрсәтү дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|
| 1 | «Тиздән мәктәпкә» | 600,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 2 | «Без мәктәпкә барабыз» | 600,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 3 | «Барысын да беләсем килә!» | 500,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 4 | «Яшь математик» | 500,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 5 | «Кызыклы грамматика» | 500,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |

2026 елның 1 январеннан

| № | Хезмәтнең исеме | Хезмәт бәясе (сум) | Хезмәт күрсәтү дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|
| 1 | «Тиздән мәктәпкә» | 650,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 2 | «Без мәктәпкә барабыз» | 650,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 3 | «Барысын да беләсем килә!» | 550,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 4 | «Яшь математик» | 550,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 5 | «Кызыклы грамматика» | 550,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |

ТР Тукай муниципаль районының
«Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү
Бәтке урта гомуми белем бирү мәктәбе»
МБГББУ директоры ______________ Р. А. Шаһимәрдәнова

«Бюджет һәм казна учреждениеләренә
хезмәт күрсәтү үзәге»
МБУ җитәкчесе урынбасары ______________ Р.Р. Йосыпова

Тукай муниципаль районының «Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү Бәтке урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ тарафыннан түләүле хезмәт күрсәтүгә бәяләр прейскурантына кушымта

1. **«Тиздән мәктәпкә»** - мәктәпкәчә яшьтәге балаларны яңа белем бирү шартларына уңышлы яраклаштыруга һәм бер белем бирү баскычыннан икенчесенә гуманлы (уңайлы) күчү шартларын булдыруга юнәлдерелгән.

Әлеге хезмәт 6 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга, кабинетның мәйданы 50,5 кв.м., балалар саны - 12.

2. **Без мәктәпкә барабыз» -** - мәктәпкәчә яшьтәге балаларның яңа белем бирү шартларына уңышлы җайлашуына һәм бер белем баскычыннан икенчесенә гуманлы (уңайлы) күчү шартларын булдыруга юнәлтелгән.

Әлеге хезмәт 6 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга бирелә, кабинетның мәйданы 48,2 кв.м., балалар саны - 9.

3. **«Барысын да беләсем килә!»** - рус теле нормаларын ныклы һәм аңлы үзләштерүгә; балалар сөйләмен үстерүгә; лингвистик анализ күнекмәләрен камилләштерүгә; укучыларның тел үсеше дәрәҗәсен күтәрүгә; рус теленә танып белү мәнфәгатьләрен тәрбияләүгә юнәлдерелгән.

Әлеге хезмәт 10 яшьтән 11 яшькә кадәрге балаларга бирелә, кабинетның мәйданы 48,2 кв.м., балалар саны – 12.

4. **«Яшь математик»** - логик фикерләүне, хәтерне, иҗади хыялны, күзәтүчәнлекне, фикер йөртү эзлеклелеген һәм аның дәлилләрен үстерүгә юнәлдерелгән.

Әлеге хезмәт 6 яшьтән 7 яшькә кадәрге балаларга, кабинетның мәйданы 45,5 кв.м., балалар саны - 16.

5. **«Яшь математик»** - укучыларның сөйләм мөмкинлекләрен исәпкә алып, инглиз телендә дөрес сөйләм күнекмәләрен үзләштерүгә, башлангыч сыйныф укучыларын чит тел коммуникацияләренә өйрәтү системасында грамматик күнекмә сыйфатында юнәлтелгән.

Әлеге хезмәт 10 яшьтән 11 яшькә кадәрге балаларга, кабинетның мәйданы 51,7 кв.м., балалар саны - 15.

ТР Тукай муниципаль районының
«Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнү
Бәтке урта гомуми белем бирү мәктәбе»
МБГББУ директоры ____________ Р. А. Шаһимәрдәнова